ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
Яңа Әхмәт авыл җирлегендә 2023 елда
гражданнарга үзара салым кертү турында

от 25 ноября 2022 г. № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы 2022 елның 24 ноябре № 1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында халык җыены

**карары:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I һәм II группа инвалидларыннан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, ел дәвамында җирлек территориясендә яшәмәүче гражданнардан (студентлар; РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче затлар, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар; хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзалары (СОП, янгыннан зыян күрүчеләрдән) тыш, 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
1) Яңа Әхмәт. авылында мультимедиа һәм музыка җиһазлары сатып алу;
2) Яңа Әхмәт авылында күмү урыннарын карау (зиярат йортын ремонтлау, койма һәм капка урнаштыру);
3) беренчел янгын куркынычсызлыгы (янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен күчмә контейнерлар сатып алу).
3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе __________ Н. И. Сахуриев
(имза)